**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлегенең Түбән Ложы торак пунктында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2023 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 13 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Түбән Ложы торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2024 елда үзара салымны 500 сум күләмендә билгеләргә һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:
- янгынга каршы резервуарны (су башнясын) буяу 15 куб.м.;
- Юл буе урамының 220 м. су үткәрү линиясен алмаштыру, янгын гидранты урнаштыру».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 120 кеше кертелгән, җыенында 72 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе буенча гражданнар җыенында катнашучыларның 64 кеше тавыш бирде;

“Каршы” дип 8 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Түбән Ложы торак пунктында гражданнар җыены үткән, гражданнар җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Түбән Ложы торак пунктында теркәлгән балигъ булган һәр гражданга, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2024 елда үзара салымны 500 сум күләмендә билгеләргә һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:
- янгынга каршы резервуарны (су башнясын) буяу 15 куб.м.;
- Юл буе урамының 220 м. су үткәрү линиясен алмаштыру, янгын гидранты урнаштыру» - дигән мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Зәй муниципаль районы**
**Бигеш авыл җирлеге башлыгы** ____________________ **И.Р.Вәлиев**